РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д.1, с.Абди, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нчы йорт, Әбде авылы, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053638 ОГРН 1061675010187 ИНН/КПП 1619004394/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 11** **2020 елның 14 август ае**

## Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Әбде авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Әбде авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:
- 1 йорт, Мәктәп ур., Әбде авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;
- Ленин ур., Әбде авылы, 15 йорт янында мәгълүмат стенды;
- М.Джалиль ур., Тактамыш авылы, 30 йорт янында мәгълүмат стенды.

2. Әбде авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июль аеның 19 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Әбде авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : 1 йорт, Школьный ур., Әбде авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Әбде авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Н.М.Домолазов